

Мин vземнен туган ягым табигатенә һәрвакыт сокланам. Сокланмаслык та тvгел бит: урман дисән, урманнары бар анын, сулыклар дисән, елга-кулләре кvп анын, таулар, болыннар, тугайлар, әрәмәлекләр... Болар барысы да минем туган ягым. Июнь - чәчәкләр ае; жәй коне нәкъ шул айдан башлана. Шушы айда болын-кырлар гына тvгел, юкәләр дә чәчәккә кvмелә. Бу айда бал кортлары армый-талмый эшлиләр, бал жыеп калырга тырышалар. Июньдә кешеләр дару vләннәре жыялар.       Чонки кvп кенә дарулар чәчәкләрдән ясала. Безнен рес-публикабызда чәчәкләрнен ниндиләре генә юк! Июнь ахырында жиләкләр дә олгерә башлый.
Июнь аен июль алыштыра. Ул сусыл тәмле жиләкләре, кызыл борлегәннәре белән килә дә, хуш исле печәннәре, тук арыш-бодайлары белән алтын козгә кереп тә китә. Боларга барысына да кешеләр генә тvгел, мал-туар да шат. Әнә, ой тирәсендә муенын горур кvтәреп йоргән ана каз бәбкәләре белән бергә бетмәс-токәнмәс авыл табигатенә хозурланып йори. Янгыры да остәмә кvркәмлелек ости тирә-ягыбызга. Бер мизгелдә яшен яшьни, коеп-коеп янгыр ява һәм кvк йозе яктырып та олгерә. Кин кvкрәк белән суларлык һава кvнелләргә рәхәтлек урнаштыра...
Тик авылда яшәп шул матурлыкларны кvрvче генә азаеп килә. Әйтеп китим, «кан тартканга» ахрысы, жәй коне халык белән тулган авыллар, табигатьтәге шикелле матурланып китә. Алар да, туган якларынын матурлыгын кvреп калырга дип, эсселе-янгырлы ямьле жәй рәхәтенә чумалар. Шагыйрьләр жәйге табигатьнен матурлыгына сокланып сvзле рәсем, ә рәссамнар картиналар язып калдыра. Без дә, сокланып калырга вакыт булган чакта, рәхәтләнеп кvзәтеп, тәмен татып калыйк ямьле жәйнен.

**Н.ХӘЛИЛ**